**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Нижнекуюкское сельское поселение Атнинского муниципального района**

422741, с.Нижний Куюк, ул. Татарстан, д.71а
Тел./факс.: (8-84369) 33247

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге**

422741, Түбән Көек авылы, Татарстан урамы., 71а йорты
Тел./факс.: (8-84369) 33247

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«18» ноябрь 2024 ел. № 8

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2024 елның 29 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пунктында үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы - Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты 29 ноябрь 2024 ел 12.30 сәг.тән 13.30 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны — Түбән Көек авылы, Татарстан урамы, 59а йорты ( Түбән Көек авылы мәдәният йорты);

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2024 елның 28 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Түбән Көек авылы, Татарстан урамы, 71а йорт;
- сайлау хокукына ия булган Түбән Көек торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Түбән Көек торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Түбән Көек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан,80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Түбән Көек авылы территориясен чистарту, үлән чабу, агачлар һәм куакларны кисү, (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); (Түбән Көек авылы балалар мәйданчыгын төзекләндерү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү));
2. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Түбән Көек авылы зиратын төзекләндерү: зиратка койма кору өчен төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
3. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, (Түбән Көек авылының урам юлларын грейдлау кардан чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү))

«РИЗА» «КАРШЫ»

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълумат-телекоммуникация челтәрендә тубәндаге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Түбән Көек авылы, Татарстан урамы, 71а йортындагы мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3.Әлеге карар ул халыкка игълан ителган көннән уз көченә керә.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Д.М. Галиәхмәтов